«Шагыйрь моңы»

Авылым тавышлары

Күңелемдә көн һаман аяз— һаман да яз
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый
Г. Тукай

Бөек Тукаебызның бу шигри юллары шундый төгәл әйтелгән. Чынлап та инде, шагыйрь күңеле аяз булмаса безнең йөрәкләребезгә үтеп керерлек шигъри юллар иҗат итә алмаслар иде. Әйтерсең лә, шагыйрьләр гади кешелек тормышында түгел, ә әллә кайларда төрле—төрле гүзәл чәчәкле, яшел болыннары булган зәңгәр болытлар артында, хыял дөньясында яшиләр. Аларның иҗатына безгә баш ияргә генә кала.

Татар халкыбыз бөек шәхесләргә бай: Халкабызны моңлы иткән Тукаебыз, батыр иткән Муса Җәлил, мәхәббәтле иткән Кол Гали. Алар бит — татарның йөзек кашлары. Шундый көчне алар каян алган, ничек шундый моңлы, батыр булалганнар?

Әлбәттә инде, бу көч халыкта, туган җирдә, туган телдә. “Халык—зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, шагыйрь ул — дигән Тукаебыз да.

27 март көнне Ләмберә балалар сәнгать мәктәбе залында әдәбият елына багышланган «Шагыйрь моңы» дигән кичә узды. Бу кичәне оештыручылар район администрациясының мәдәният бүлеге һәм татар милли мәдәният үзәге.

Чакырылган кунаклар арасында Ләмберә муниципаль район администрация башлыгы Фатих улы Шамиль Давыдов, «Юлдаш» исемендәге крестьян—фермер хуҗалыгының җитәкчесе Айяз улы Рәфик Фетхуллов, Ләмберә авыл администрация башлыгы Фатих улы Руслан Курмакаев һәм Казан шәһәреннән килгән язучылар «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать Эшлек—лесе», Татарстан язучылар берлегенең рәисе — Харис улы Рафис Корбанов.

«Татарстан республикасының атказанган мәдәният Эшлек — лесе», Татарстан язучылар берлегенең идарә әгъзасы, әдәбият тәнкыйтьчесе — Харис улы Мөдәррис Вәлиев.

Залда утыручылар — район мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбият укытучылары, балалар, мәдәният һәм китапханә хезмәткәрләре.

Кичәне Г. Тукайның «Туган тел» шигырен укып ачып җибәрделәр иң яшь катнашучы балалар: Ибрагим Биктимиров һәм Хәсан Максимов.

Рафис Корбанның «Ватан” һәм “Туган тел” шигырен сөйләделәр Зиче сыйныф укучылары Раиль Юмаев һәм Самира Максимова.

Казаннан килгән язучыларга бераз гына үз эшебез турында, районда һәм авылда милли мәдәният үсешенә ничек игътибар бирелүен, нинди бәйрәмнәр оештырылуын сөйләдек.

Эшебезнең төп максаты: татар халкыбызның бай тарихын, туган телне, әби—бабаларыбыздан калган гореф—гадәтләрне саклап калу һәм яшь буынга тапшыру дип әйттек. Бу сүзләрне исбатлап Алсу Батерякова Г. Тукайның «Милли моңнар» шигырен укыды.

Ксения Громова татар халык «Сарман» җырын җырлап татар җырларыбызның матурлыгын, аларны башка милләт халкы да кызыксынып тыңлавы һәм башкаруы аңлатты.

Шулай ук, тыңлаучының тынын яулап Гүзәл Казакова Р. Яхинның «Ялгыз агач» дигән җырын башкарды.

Район мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбият ничек укытылуы турында чыгыш ясады Якуб кызы Наиля Усманова.

Чермиш мәктәп укытучысы Фәрит кызы Фазия Боярова үз чыгышында укытучы һөнәренең иң мөһиме—балаларда туган телгә мәхәббәт тудыру, бүгенге көндә ул үз укучылары белән горурлана ала дип әйтте һәм балалары сугыш темасына багышланган «Кызыл алмалар» исемле сценка күрсәттеләр.

Солдатов Илдар Муса Җәлилнең «Кичер, илем» дигән шигырен укыды. Шулай ук зал тын калып Нурия Искандярова башкаруында М. Җәлилнең «Бүреләр» шигырен тыңлады.

Быел Бөек Ватан сугышында җиңүгә 70 ел була.

Сугыш... Бу сүзне ишеткәч тә тетрәнеп куясың. Еллар узган саен йөрәк яралары сызлавы кимергә тиеш иде дә... Юк. Онытылмый, онытырлык түгел бу көн өчен күпме кан яшь җиргә түгелгән...

Сугыш темасыннан соң үз якташларыбыз: Һ. Такташ, Ш. Камал, Г. Әпсәләмов һәм башка язучыларны искә алыр өчен сүз бирелде 56 ел буе районыбызда һәм республикада милли мәдәният үсешенә зур өлеш керткән хезмәт ветераны, фольклор «Дуслык» ансамбленең җитәкчесе Али кызы Рәшидә Ипкаевага.

Кичәне дәвам иттеләр Казаннан килгән кунаклар: балалар шагыйре һәм драматург Рафис Харис улы Корбанов. Ул башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Күп төрле газета — журнал редакцияләрендә эшли.

Балалар өчен язылган «Капкорсак» китабы өчен автор 1993 елда Ш. Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек була, шулай ук ул Татарстан язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләк иясе (2003 ел). Ул лирик һәм публицистик шигырьләр, җыр текстлары авторы буларак та билгеле. Аның күп кенә лирик шигырьләренә профессиональ һәм үзешчән композиторлар тарафыннан көйләр языла.

Аларның берсен Ф. Әхмәтҗанова музыкасына куелган «Әни теләкләре» дигән җырын башкарды «Умырзая» ансамбленең җитәкчесе Фаиля Равилова.

Икенче кунак язучыбызның чыгышын башладык аның «Әни» дигән шигыре белән.

Әдәбият тәнкыйтьчесе (критик), шагыйрь Мөдәррис Харис улы Вәлиев (әдәби тәхәллүсе — Салих Маннапов) 1971-1976 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр язган һәм республика яшьләр—балалар матбугатында исеме күренә башлаган. Мөдәррис университет студентларының атаклы «Әллүки» әдәби түгәрәген җитәкли. Мөдәррис Вәлиев матбугат, мәгариф һәм әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлек—лесе» дигән мактаулы исемгә (1989) һәм М.Җәлил исемендәге Республика Яшьләр премиясенә (2003) лаек була.

Очрашу бик мавыктыргыч, озакка истә калырлык булып үтте дип — әйтте Рафис Корбан.

Укучыларыбыз да кунаклар алдында тамашачы булып кына утырмадылар, аларга әдәбияттан булган белемнәрен күрсәттеләр.

Һ. Такташның «Алсу» поэмасыннан өзекне укыды Тавла Мәктәп укучысы Хамидуллова Рената.

М. Җәлилнең «Кошчык» һәм «Соңгы җыр» шигырьләрен сөйләделәр Кырви мәктәп укучылары Каримова Кадрия һәм Карабанова Ленизә.

Габд. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романыннан «Гөлшаһидә» җырын җырлады «Дуслык» ансамбленең солисткасы Наиля Байбикова.

Балаларга бигрәк тә Рафис абыйларының табышмаклары һәм бүләккә биргән китаплары ошады.

Милли мәдәният үзәгенең методисты Алсу Сюбаева һәм китапханә хезмәткәрләре оештырган китап күргәзмәсе дә Татарстан кунакларына бик ошады.

Бу кичәнең истәлеге итеп килгән кунакларга татарча бастырылган «Шагыйрь моңы» дигән блокнотлар һәм картиналар бирелде.

Кичәне Г. Тукайның Халкыбыз теленә гимн булып әверелгән «Туган тел» җыры белән тәмамладык.

Татар битен җыештыручы
Альфия Максимова

Районда татар телен саклап калуда һәм милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән, күп еллар татар телен һәм әдәбиятны тырышып укыткан укытучылар Якуб кызы Наиля Усмановага һәм Фәрит кызы Фазия Бояровага (фотографиядә) Альфия Максимова татар милли мәдәният үзәге исеменнән благодарностьләр һәм бүләкләр бирде.

Чермиш мәктәп укучылары «Кызыл алмалар» дигән күренештә.

«Рәхмәт сезгә, ветераннар!»

5 апрель көнне Саранск шәһәренең «Ускудар» мәчетендә «Бөек Ватан сугышындагы җиңүдә Ислам диненең әһәмияте» дигән семинар үткәрелде. Семинарга 300 дән артык кеше чакырылган иде. Бу чараны оештыручылар – Мордовия республикасы мөселманнарының региональ дини оешмасының муфтие Зәки хәзрәт Айзатуллин.

Очрашуда сугыш ветераннарын тантаналы рәвештә бүләкләү өчен Россия Федерациясенең җәмгыяви палата әгъзасы, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенең муфтие — Крганов Альбир Рифкатович, Лямбәрә муниципаль администрациясенең башлыгы Фатих улы Шамиль Давыдов һәм башка рәсми шәхесләр килгән иде.

Зәки Айзатуллин Бөек Ватан сугышындагы җиңүдә мөселманнарның зур өлеш кертүен әйтте һәм аларга дөньяга тынычлык алып килгән өчен зур рәхмәтләрен белдерде.

Ветераннар да бу чараны оештыручыларга зур рәхмәтләрен белдерделәр. Очрашу бик җылы, мавыктыргыч рәвештә уза. Үткәннәрне искә алып, бер бересемән аралашып вакытның узганын да сизмиләр. Кичә ахырында шәһәрдән, Азерка авылы мәктәбеннән һәм Ялга интернатыннан килгән балалар ветераннар өчен концерт куйдылар.

Афиша

БУИНСКИЙ ТЕАТР САТИРЫ

23 апреля в 18.30
Юмористический концерт **«ЕЛМАИ»**
на татарском языке

24 апреля в 18.30
комедия
«Булса да була икән»
на татарском языке

Мордовский Государственный национальный драматический театр
ул. Советская, д. 27 касса: 38-07-03